ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

11 август, 2020 ел № 41/14

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советы депутаты статусы турында Нигезнамәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә
Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының 2011 елның 26 маендагы 12/7 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советы депутаты статусы турында Нигезнамәгә (Шәһәр Советының 2016 елның 7 апрелендәге 7/20, 2018 елның 21 февралендәге 23/12, 2018 елның 8 ноябрендәге 27/22, 2019 елның 6 декабрендәге 34/15, 2020 елның 17 июнендәге 40/4 номерлы Карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 3 статьяга түбәндәге эчтәлекле 6 өлеш өстәргә:

«6. Шәһәр Советы депутатының вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында Шәһәр Советы карары вәкаләтләрне вакытыннан алда туктату өчен нигез барлыкка килгән көннән соң 30 көннән дә соңга калмыйча, әгәр бу нигез Шәһәр Советы утырышлары арасында барлыкка килгән булса, мондый нигез барлыкка килгәннән соң өч айдан да соңга калмыйча кабул ителә. »;

2) 12 статьяга түбәндәге эчтәлекле 5 өлеш өстәргә:

«5. Депутат шәһәр Советы Президиумына сайлау округында үз эше турында хәбәр итә. Күрсәтелгән мәгълүматны бирү тәртибе Шәһәр Советы Президиумы тарафыннан раслана.»;

3) 13 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Шәһәр Советы депутаты депутат фракциясе яки уртак эшчәнлек һәм карала торган мәсьәләләр буенча позицияне белдерү өчен төзелә торган төркем составына керергә хокуклы.

2. Фракцияләр һәм башка депутат берләшмәләрен төзү, теркәү һәм аларның эшчәнлеге тәртибе шәһәр Советы Регламенты белән билгеләнә.»;

4) 20 статьяда:

- беренче абзацта «дүрт» сүзен «ике»  сүзенә алыштырырга;

- түбәндәге эчтәлекле өченче, дүртенче абзац өстәргә:

«Депутат ярдәмчесе тарафыннан үз статусын шәхси мәнфәгатьләрдә файдалану рөхсәт ителми.

Депутат ярдәмчесенең эшчәнлеге депутатның вәкаләтләре туктатылу белән бер үк вакытта яйсә якларның берсе тарафыннан муниципаль берәмлек Башлыгы урынбасарына тапшырыла торган белдерү кәгазе белән вакытыннан алда туктатыла.».

2. Әлеге Карар үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының регламент, хокук тәртибе һәм халык иминлеген тәэмин итү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев